КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 март г.Казань № 110

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы; 2019 ел, 3 апрель, 262 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче; 2020 ел, 25 июнь, 525 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләргә:

2018 елның 1 апреленнән – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 1 512,069 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 82 берәмлек;

2020 елның 1 октябреннән – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 1 559,094 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 82 берәмлек күләмендә;

2021 елның 1 мартыннан – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 1 377,800 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 71 берәмлек.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Баш ветеринария идарәсе түбәндәге функцияләрне башкару өчен җавап бирә:

ветеринария идарәсе (03.02.04*);

хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге (03.02.04.1*).»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Баш ветеринария идарәсе үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән Татарстан Республикасында халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02.09*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02.01*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән финанс-бюджет өлкәсендә контроль функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.01*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән цифрлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.01*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*).»;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

---

*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

үсемлекләр дөньясыннан файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.06.03*);

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү мохитен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләрендә урнашкан хайваннар дөньясы объектларыннан һәм аларның яшәү мохитеннән тыш) тапшырылган вәкаләтләр чикләрендә федераль дәүләт күзәтчелеге (01.06.12*).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин